ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2018 Казан ш. № 5-101/тэ

«РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятеннән кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) 2019 елга тарифлар билгеләү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгына, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «2033 елга кадәр Казан шәһәре муниципаль берәмлеген җылы белән тәэмин итүнең актуальләштерелгән схемасын раслау турында» 2018 елның 16 августындагы 658 номерлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятеннән кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә), шушы карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 нче пунктында билгеләнгән тарифлар 2019 елның 1 гыйнварыннан башлап 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018№ 5-101/тэ карарына кушымта

## «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятеннән кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) 2019 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы, Тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче hәм редукцияләш-терүче пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см2 кадәр | 2,5тән 7,0 кг/см2 кадәр | 7,0дән 13,0 кг/см2 кадәр | югары 13,0 кг/см2 | |
| | Казан шәhәре | | | | | | | |
| 1 | «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 1478,41 | - | – | – | – | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 1520,45 | - | – | – | – | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 1774,09 | - | – | – | – | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 1824,54 | - | – | – | – | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту hәм теркәү бүлеге